ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ГОРОДА МЕНЗЕЛИНСКА МЕНЗЕЛИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКСЫ МИНЗӘЛӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МИНЗӘЛӘ ШӘҺӘРЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

04.05.2026 № 114

Ачык тыңлауларны билгеләү турында

"Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының "Минзәлә шәһәре" муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре нигезендә, "кибетләр" шәхси торак йортлар төзелеше зонасында - «Татарстан Республикасы, Минзәлә муниципаль районы, Минзәлә шәһәре, М. Җәлил урамы, 134Б адресы буенча урнашкан 2340 кв.м мәйданлы 16:28:180145:478 номерлы җир кишәрлегеннән файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турында»

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына ярашлы рәвештә, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законы, Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Минзәлә шәһәре муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Минзәлә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе **карар бирде:**

1. "Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының "Минзәлә шәһәре" муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре нигезендә, "кибетләр" шәхси торак йортлар төзелеше зонасында - «Татарстан Республикасы, Минзәлә муниципаль районы, Минзәлә шәһәре, М. Җәлил урамы, 134Б адресы буенча урнашкан 2340 кв.м мәйданлы 16:28:180145:478 номерлы җир кишәрлегеннән файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турында» ачык тыңлаулар уздыруны билгеләргә.

2. Ачык тыңлауларны оештыручы составын - коллегиаль киңәшмә органын расларга:

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Чухланцев Д. А.;

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының «Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы» МКУ рәисе Р. С. Шакиров;

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Башкарма комитетының төзелеш, архитектура һәм ТКХ бүлеге башлыгы урынбасары - баш архитектор Петров В.К.

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Башкарма комитетының төзелеш, архитектура һәм ТКХ бүлеге башлыгы Басков Е. А.,

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Советының юридик сектор мөдире Петрова А.В.

3. Ачык тыңлауларны оештыручыга ачык тыңлауларны җирле үзидарә турындагы, шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы кануннар нигезендә оештыруны һәм уздыруны тәэмин итәргә.

4. Ачык тыңлаулар үткәрү вакытын 2026 елның 12 маеннан 2026 елның 22 маена

кадәр билгеләргә. Ачык тыңлаулар үткәрү вакытын 2026 елның 22 маена кадәр билгеләргә.

5. Әлеге карар рәсми рәвештә бастырылып чыгарга тиеш.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче Р. Р. Шәйсуваров